Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение

«Нижневязовская начальная общеобразовательная школа ЗМР РТ»

«Согласовано»

Руководитель МО

_____/ Барскова Ю.А./

Протокол № 1 от

«07» 08 20 г.

«Утверждаю»

Директор МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

_____ /Салахеева Г.А./

Приказ № _____ от

«07» 08 2023г.

# Рабочая программа

Учебного предмета, курса, дисциплины (модуля)

МБОУ «Нижневязовская НОШ» ЗМР РТ

Насибуллиной Раиси Рифатовны

Ф.И.О., категория

Родной язык (татарский) 3 класс

предмет, класс.

## ПОЯСНИТЕЛЬНАЯ ЗАПИСКА

Целью программы является развитие устной и письменной речи учащихся, совершенствование речевой деятельности по всем ее видам, формирование и развитие лингвистической компетенции.

Задачи изучения учебного предмета следующие:

- обеспечение мотивации обучения родному языку;
- формирование первоначальной лингвистической компетенции по всем уровням татарского языка;
- воспитание положительного ценностного отношения и уважения к родному языку;
- формирование гражданских и патриотических чувств;
- овладение умениями связной устной и письменной речи;
- развитие культуроведческой компетенции учащихся.

## 1. ПЛАНИРУЕМЫЕ ПРЕДМЕТНЫЕ РЕЗУЛЬТАТЫ ОСВОЕНИЯ УЧЕБНОГО ПРЕДМЕТА «РОДНОЙ (ТАТАРСКИЙ) ЯЗЫК»

Планируемые предметные результаты освоения с учетом общих требований Стандарта и специфики учебного предмета «Родной (татарский) язык» должны обеспечивать успешное обучение на следующей ступени общего образования:

- овладение первоначальными знаниями о единстве и многообразии языкового и культурного пространства народов Российской Федерации;
- осознание языка как значимой части национальной культуры, как средства общения между разными народами;
- воспитание позитивного отношения к овладению литературными нормами устной и письменной речи;
- овладение орфоэпическими, лексическими и грамматическими нормами татарского языка, первоначальными сведениями о татарском речевом этикете, умение выборочного использования языкового материала, необходимого для коммуникации в объеме изученного программного материала;

- использование полученных знаний по татарскому языку в познавательной и коммуникативной деятельности при различных жизненных ситуациях (в учебном процессе и во внеклассных мероприятиях).

В результате усвоения татарского языка учащиеся осознают язык как средство коммуникации, как национально-культурный феномен.

## 2. СОДЕРЖАНИЕ УЧЕБНОГО ПРЕДМЕТА «РОДНОЙ (ТАТАРСКИЙ) ЯЗЫК»

Материал учебного предмета «Родной (татарский) язык» для 3 класса общеобразовательных организаций с обучением на русском языке структурирован в соответствии с видами речевой деятельности и следующими разделами языкознания: фонетика и орфография, лексикология, морфемика и словообразование, морфология, синтаксис, орфография и пунктуация, развитие речи.

**Аудирование.**

Понимание содержания прослушанного текста, ответы на вопросы по его содержанию, проведение беседы с целью определения основной мысли текста.

**Говорение**.

Использование изученных языковых единиц с учетом речевой ситуации. Составление диалогической и монологической речи с соблюдением орфоэпических и интонационных норм родного языка. Использование образцов татарского речевого этикета по различным темам в учебном процессе и во внеклассных мероприятиях.

**Чтение**.

Понимание содержания прочитанного текста с соблюдением орфоэпических норм, определением логического ударения. Определение темы и основной мысли текста. Осознанное чтение слов, словосочетаний, предложений и коротких текстов. Чтение с соблюдением нужной интонации и паузы в соответствии с проставленными знаками препинания. Осознанное и выразительное чтение небольших текстов и стихотворений.

**Письмо**.

Формирование навыков письма слов и предложений. Письмо под диктовку и переписывание текста на изученное правило. Составление небольшого письменного текста на основе просмотренной картины (рисунка) или видеозаписи, с привлечением увиденного (услышанного) материала.

**Слово и предложение**.

Лексическое значение слова. Выделение слова из предложения. Наблюдение над порядком расположения слов в предложении. Изменение порядка слов в предложении.

**Орфография**. Ознакомление с правилами орфографии:

• раздельное написание слов;

• написание букв **о** и **ө** в первом слоге татарских слов;

• заглавная буква в начале предложения, знаки препинания – точка, вопросительный и восклицательный знаки в конце предложения;

• деление слов на слоги, перенос слов по слогам.

**Развитие речи**. Понимание содержания прочитанного или прослушанного текста. Составление небольших текстов с использованием сюжетных картин, на основе личных наблюдений.

**Систематический курс**

**Лексика**.

Слово как единство произносимого и значимого. Определение семантики слова по толковому словарю. Наблюдения над однозначными и многозначными словами, над употреблением речи синонимов и антонимов.

**Состав слова.**

Понятие об однокоренных словах, их отличия от синонимов и омонимов. Определение корня слова и аффикса. Понятие о словообразовательных аффиксах. Выполнение упражнений с элементами словообразовательного анализа.

**Морфология**.

Понятие о частях речи. Имя существительное, его значение и употребление в речи. Вопросы имен существителных. Определение имен существительных, отвечающих на вопросы кем? нәрсә? Собственные и нарицательные имена. Формы единственного и множественного числа. Названия и вопросы падежей. Склонение имен существительных. Имена с аффиксами притяжательности. Выполнение упражнений на морфологический анализ существительных.

Имя прилагательное: его значение и употребление в речи. Вопросы прилагательных, выражение различных признаков предметов. Степени сравнений имен прилагательных. Выполнение упражнений на морфологический анализ имен прилагательных.

Местоимения. Понятие о местоимениях. Личные местоимения: значение, употребление в речи, формы единственного и множественного числа, склонение личных местоимений.

Глагол. Значение глагола и употребление в речи. Определение глаголов, отвечающих на вопросы *нишли?* (что делает?), *нишләде?* (что делал?), *нишләр?* (что будет делать?). Спряжение глаголов. Формы настоящего, прошедшего и будущего времени. Утвердительная и отрицательная формы глаголов. Выполнение упражнений на морфологический анализ глаголов.

Наречие. Его значение, вопросы, употребление в речи.

Послелоги, их значение в речи.

Частицы *да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*. Правописание частиц.

**Синтаксис**.

Выделение слов, слосочетаний и предложений. Разные по цели высказывания предложения, знаки препинаний при них. Чтение различных коммуникативных предложений с соответствующей интонацией.

Понятие о главных членах предложения. Определение связи слов в словосочетаниях и предложениях с помощью наводящих вопросов.

Определение предложений с однородными членами с союзами *һәм, ә, ләкин*. Составление собственных предложений с союзами и без них с интонацией перечисления.

Определение простых и сложных предложений.

**Развитие речи**.

Выражение своего мнения с учетом ситуации, цели и адресата общения. Аргументированное выражение своего мнения. Овладение основными элементами проведения беседы: вводное слово, поддержание темы и ее продолжение, привлечение внимания собеседника и т.д. Усвоение норм татарского речевого этикета в процессе повседневной учебной деятельности и во внеклассных мероприятиях: приветствие, прощание, извинение, благодарение, обращение с просьбой и др. Особенности татарского речевого этикета при общении с собеседником, уровень владения которого не всегда соотвествует требованиям программы. Составление собственных речевых (монологических) высказываний описательного или оценочного характера.

## 3 класс

## Слово

Слово единство произносимого и семантического. Прямое и переносное значение слова. Синонимы, омонимы и антонимы.

Ознакомление со словарями, формирование умение работать с ними. Словрные диктанты.

**Состав слова и словообразование.**

Корень и аффикс. Производные слова. Однокоренные слова. Особенности присоединения аффиксов в татарском и русском языках. Сложные и парные слова.

**Морфология.**

Нарицательные и собственные **имена сущствительные.** Склонение имен. Особенности склонения имен существительных на носовые согласные.

**Прилагательные.**

Синонимы и антонимы. Употребление прилагательных в предложении. Особенности синтаксической связи между прилагательным и существительным в татарском языке.

**Имя числительное,** его значение, вопросы. Особенности синтаксической связи между числительным и существительным в татарском языке

**Местоимение.**

Склонение личных местоимений. Понятие о вопросительных местоимениях.

**Глагол.**

Спряжение глаголов изъявительного наклонения. Сопоставление с временными и личными формами глаголов татарского и русского языков.

**Синтаксис.**

Составление словосочетаний и предложений с использованием изученных частей речи.

Предложения по цели высказывания: повествовательные, вопросительные, повелительные, восклицательные. Определение главных членов предложения.

Понятие об определении. Особенности синтаксической связи между определением и определяемым словом в татарском языке.

Порядок слов (подлежащего и сказуемого, определения и определяемого слова) в татарском языке.

**Обобщенное повторение за год.**

**Развитие связной речи.**

**Аңлатма язуы**

Эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:
1. Россия Федерациясенең “ Мәгариф турында” законы, декабрь, 2012 ел.
2. Татарстан Республикасының “Мәгариф турында” законы, 2013 ел.
3 “Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы законы (2004 ел, 1 июль).
4. Рус телле балаларга татар телен һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы. 1-11 нче сыйныфлар , Казан: Татар китап нәшрияты, 2011. Төзүчеләр: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән)

Дәреслек :Р.З. Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина “Күңелле татар теле”. Дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче сыйныф рус балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге. Дәреслек Татарстан Республикасы мәгариф+ һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән. Ике кисәктә. Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 ел.

**Арадаш аттестация** контроль диктант формасында еллык календарь графикка туры китереп үткәрелә.

## Белем бирүнең максатлары

**Төп максат** – иҗади фикерләүче, инициативалы, иҗтимагый тормышта актив катнашучы, белемле һәм ике дәүләт телендә дә иркен сөйләшеп аралашучы шәхесләр тәрбияләү.

Рус балаларына татар теле укыту максаты күпкырлы һәм ул берничә аспекттан тора: танып белү, үстерү, тәрбия, белем бирү.

### 1. Танып белү максаты

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Программа эчтәлеге телгә өйрәтү процессын бала өчен “башка дөньяга тәрәзә ачу” (И.Л.Бим) булырлык һәм шуның аркылы аның үз яшәешен дә тулырак аңлавына ярдәм итәрлек итеп сайланды.

Татар исемнәрен, Татарстанның табигатен, җирлеген, топонимикасын дөрес әйтә белергә өйрәтү, аларның семантикасы белән кызыксындыру, балалар фольклоры, татар халкы авыз иҗаты, әдәбият-сәнгать вәкилләре белән беренчел таныштыру - башлангыч этапта танып белү максатының төп эчтәлеген тәшкил итә.

### *2.* Үстерү максаты

Шәхеснең белемле булуы, тәрбиялелек һәм аның фикерләү сәләте үсеше дәрәҗәсеннән дә тора. Укыту процессында үстерү, тәрбия максатларын даими күзаллап
эшләү - укытуның практик ягы уңышлылыгының алшарты (Л.С.Выготский). Бу хакыйкатьне балаларның белем алу эшчәнлегенең барлык этапларында да истә тоту зарур.

Балаларның психик үсешен түбәндәге юнәлешләрдә үстерүгә аеруча игътибар таләп ителә:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дидуктив фикерләү;
- хәтерне үстерү (ихтыярый, ихтыярсыз), игътибарлылыкны үстерү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне үстерү.

### 3. Тәрбия максаты

Башка милләт вәкилләренең күңелен яулардай, аларда гомумкешелек әхлакый сыйфатлары тәрбияләрдәй татар әдәбияты өлгеләре белән таныштыру да шушы ук максатка буйсындырылган һәм сөйләшү - аралашуга алып чыгуга кулайрак булган әдәби әсәрләрнең авторлары белән таныштыру.

### 4. Белем бирү максаты

Укучыларның татар теле буенча лексик, грамматик күнекмәләре филологик белемнәр суммасы дәрәҗәсендә генә калмыйча, ә сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләрендә дә аралашуда кулланырлык дәрәҗәгә җитүе зарур. Ягъни, укучылар, нинди дә булса сүзне, я грамматик категорияне тану, аеру, аңлау, тәрҗемә итү дәрәҗәсендә генә түгел, аларны аралашу максатында мөстәкыйль кулланырлык дәрәҗәдә өйрәнергә тиешләр. Шул вакытта гына татар телен дәүләт теле буларак өйрәнү бурычы үтәлә.

**Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала**:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләре булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау, чакыру кәгазьләре язу;
- конверт һәм дәфтәр тышына яза белү;
- программа күрсәтелгән темалар буенча терәк сүзләр кулланып, хикәя язу күнекмәләре формалаштыру.

## Программаны үзләштерүдән көтелгән нәтиҗәләр

Төп гомуми белем бирү мәктәбендә телне гамәли үзләштерү нәтиҗәсендә укучыларда татар теленең күп мәдәниятле дөньядагы роле һәм мөһимлеге турында күзаллаулар формалаша. Татар мәдәниятенең укучылар өчен булган катламы белән танышу башка мәдәнияткә карата ихтирам хисе уята, ягъни укучыларга үз мәдәниятләрен дә тирәнрәк аңларга мөмкинлек бирә, аларда ватанпәрвәрлек хисе уята.

**Гомуми нәтиҗәләр:**

- укучыларның коммуникатив компетенциясен (аралашу осталыгын) үстерү, ягъни татар телендә сөйләшүчеләр белән телдән яки язмача аралашу күнекмәләре булдыру;
- коммуникатив бурычлар куя һәм хәл итә белү, адекват рәвештә аралашуның вербаль һәм вербаль булмаган чараларыннан, сөйләм этикеты үрнәкләреннән файдалана алу, итагатьле һәм киң күңелле әңгәмәдәш булу;
- татар теле предметына карата уңай мотивация һәм тотрыклы кызыксыну булдыру һәм шулар нигезендә белем алуның алдагы баскычларында татар телен уңышлы үзләштерергә шартлар тудыру.

**Шәхси нәтиҗәләр:**

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;

– әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
– әдәби әсәрләрдәге төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү.

## Метапредмет нәтиҗәләр

***Танып белү***

– фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
– классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
– ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;
– үрнәк буенча эшли белү;
– аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
– рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
– укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

***Регулятив***

– уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
– уку эшчәнлеге нәтиҗәләрен контрольгә ала белү;
- укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
- дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү.

***Коммуникатив* нәтиҗәләр:**

– әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
– аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

## 3 нче сыйныф укучылары белергә тиешле төшенчәләр

***Грамматик минимум:***

1. Исемнең иялек килешендә төрләнеше белән таныштыру.
2. Зат алмашлыкларын күплек санда юнәлеш килешендә сөйләмдә куллану.
3. Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең барлыкта зат-сан белән төрләнеше.
4. Билгесез үткән заман хикәя фигыльнең барлык һәм юклык формасы белән текст аша танышу.
5. Уйнарга яратам конструкциясе белән таныштыру.
6. Синоним һәм антоним сыйфатларны сөйләмдә куллану.
7. Янында, алдында, астында, артында, өстендә, турында бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
8. Ләкин, чөнки, шуңа күрә теркәгече, кушма җөмләләрнең эчтәлеген аңлап, аларны сөйләмдә куллану.

9. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатлар белән танышу.
10. Сүзнең тамыры, кушымчасын аера белү.
11. -чы/-че- исем ясагыч кушымчалар белән таныштыру .
12. Кебек бәйлеген сөйләмдә куллану.
13. Казан шәһәре, киемнәр кибете төзелмәләре белән таныштыру.
14. Аннан соң рәвеше һәм һәр, һәркем, барлык, барысы алмашлыклары белән таныштыру.

***Орфографик Һәм орфоэпик минимум:***

1. Өйрәнелгән лексик берәмлекләрне орфоэпия нормаларына туры китереп әйтүне ныгыту.
2. Алынма сүзләрне дөрес әйтелешен саклап, сөйләмдә куллanyрга күнектерү.
3. Укучыларның язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен камилләштерү эшен дәвам итү.
4. Ике бертөрле тартык янәшә килгән сүзләрне дөрес әйтү һәм язу күнекмәләрен булдыру (китте, кайтты).
5. Янәшә килгән ике бөртерле тартык булган сүзләрне дөрес әйтергә өйрәтү.
6. Я, ю, е хәрефләре кергән сүзләрнең әйтелешен һәм язылышын истә калдыру.
7. О, ө хәрефләренең беренче иҗектә генә язылуы.

**Программаның эчтәлеге**

| № | Бүлекләр, темалар | Сәгать саны | Темага караган төп төшенчәләр |
|---|---|---|---|
| 1. | Белем бәйрәме | 16 | Исемнәрнең берлек, күплек саны, тартым белән төрләнеше, урын-вакыт килеше, юнәлеш килеше, чыгыш килеше, сорау алмашлыклары, хәзерге заман хикәя фигыль 2 формада 4 затта, җыю саннары |
| 2 | Көндәлек режим | 2 | Сәгать ничә икәнен, эшнең сәгать ничәдә башкарылганын сөйләмдә куллану |
| 3 | Ашханәдә | 8 | Җыйнак һәм җәенке җөмләләр, кайчан, нинди сораулары,исемнәрнең килеш белән төрләнеше, билгесез үткән заман хикәя фигыльләр |
| 4 | Без әти- әниләргә булышабыз | 7 | Сорау җөмләләр, саннарның төрләре. Исемнең 3 зат тартым кушымчалары, антонимнар |
| 5 | Туган якка кыш килде | 9 | Инфинитив фигыльләр, хәзерге заман, үткән заман хикәя фигыльләр, фигыльләрне 1-3 затларда куллану |
| 6 | Шәһәрдә һәм авылда | 5 | Татар телендә сингармонизм законы, -чы/-че сүзъясагыч кушымчалары |
| 7 | Әдәпле булыйк | 5 | Алмашлыкларның килеш белән төрләнеше, исемнең тартым белән төрләнеше, тәртип саннары |
| 8 | Кечкенә дусларыбыз | 6 | Җөмлә төрләре, татар теленә хас авазлар, ялгызлык һәм уртаклык исемнәр |
| 9 | Күңелле җәй | 10 | Җөмләдә сүзләр тәртибе, сыйфат дәрәҗәләрен кабатлау, кушма сүзләр |
| | **Барлыгы** | **68** | |

## Календарь – тематик план

| № | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Сә-гать саны | Үткәрү вакыты | | Көтелгән нәтиҗәләр | | Универсаль уку гамәлләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Кален-дарь | Фак-тик | белем | күнекмә | |
| **Тема “Белем бәйрәме”(16 сәгать)** | | | | | | | |
| 1. | Авазлар һәм хәрефләр. Татар теленә генә хас авазлар | 1 | | | Бүген, белем бәйрәме, башлана, хөрмәтле, котлыйм, уңышлар телим кебек лексиканы өйрәнү | Беренче сентябрь – белем бәйрәме турында сөйләү, бәйрәм белән котлау | Сорауларга җавап бирү, котлау язу, сөйләм эшчәнлеген формалаштыру |
| 2. | Исем сүз төркеме | 1 | | | Кем? Кемгә? кемне? Сорауларын аңлый, аларга җавап бирә белү | Син, сез алмашлыкларын төшем, юнәлеш килешендә куллану | 1 сентябрь – Белем бәйрәме белән котлау, бер–береңә комплимент әйтү |
| 3 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары һәм аларга җавап | 1 | | | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары һәм аларга җавап бирә белү | Мәктәпкә барганны, анда укыганны һәм кайтканны әйтү | Сюжетлы рәсем буенча җөмләләр төзү, сүзлек белән эшләү |
| 4 | -мы/-ме сорау кисәкчәсе | 1 | | | -мы/-ме сорау кисәкчәсе турында төшенчә бирү. Китап, дәфтәр, каләм, өстәл, бетергеч кирәк, кирәкми, түгел, бир әле сүзләрен өйрәнү | Уку-язу әсбапларының кемгә икәнен, аларның барлыгын, юклыгын, кирәклеген хәбәр итү (сорау), үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкъдим итү | -мы/-ме сорау кисәкчәсенең кулланылышына күнегүләр башкару |
| 5 | Исемнең күплек сан кушымчасы | 1 | | | -лар/-ләр, -нар/-нәр күплек сан кушымчалары төшенчәсе | Предметларның төсен, санын кулланып үзеңә сорау күнегүләре | “Миңа биш кызыл каләм бир әле” төзелмәләренә сорау күнегүләре башкару |
| 6 | Исем сүз төркеме | 1 | | | Исем сүз төркемен өйрәнү | Бер-береңнең хәлен сорау, комплимент әйтү | Рәсем буенча җөмләләр төзү |
| 7 | Тартым алмашлыклары | 1 | | | Тартым алмашлыкларын өйрәнү | Үзеңнең, дусларыңның уку-язу әсбапларының кемнеке икәнен әйтү | Тартым алмашлыклары белән мисаллар әйтү, диалог төзеп сөйләү |
| 8 | Хәзерге заман хикәя | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыль белән | Ничәнче сыйныфта | Хәзерге заман хикәя |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | фигыль | | | | танышу | укыганыңны, сыйныф турында сөйләү | фигыльләрне текстан табу |
| 9 | Үткән заман хикәя фигыль | 1 | | | Үткән заман хикәя фигыль формасы, зат – сан төрләнешен белү | Үзең турында, кизү тору турында сөйләү, | Хикәя төзеп сөйләү, сорауларга җавап бирү |
| 10 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасы | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыленең юклык формасы турында төшенчә | Үзеңнең, иптәшеңнең нинди эшләр эшләгәнен, эшләмәгәнен әйтү. | Хикәя уку, бәя бирү, диалог төзеп сөйләү |
| 11 | Чөнки, ләкин теркәгечләре | 1 | | | Чөнки, ләкин теркәгечләре турында төшенчә | Җөмләләргә сораулар кую, бер-береңә сораулар бирү | Чөнки, ләкин теркәгечләрен табу һәм дөрес куллану |
| 12 | Сингармонизм законы | 1 | | | Сингармонизм законы, үзе алмашлыгы турында төшенчә | Үзеңнең, иптәшеңнең уку хезмәте турында сөйләү | Сүзләрне иҗеккә бүлү, калын һәм нечкә сузыкларны билгеләү |
| 13 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнеше | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең берлек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнешен белү | Үзеңнең, иптәшеңнең уку хезмәтен, өй эшен эшләгәнен, мисал, мәсьәлә чишкәнен сорау, әйтү | Ишетеп аңлау күнегүләре, җөмләләр төзү, диалог төзү, язу күнегүләре |
| 14 | Ярдәм ит әле, ярдәм итегез әле төзелмәләре | 1 | | | Ярдәм ит әле, ярдәм итегез әле төзелмәләрен өйрәнү | Үзеңә ярдәм сорау | Ярдәм ит әле, ярдәм итегез әле төзелмәләрен куллану |
| 15 | Янында бәйлек сүзе | 1 | | | Янында бәйлек сүзе, исемнәрне юнәлешендә төрләндерә белү | Китапханәгә барырга чакыру | Китапханәгә барганыңны, бармаганыңны әйтү |
| 16 | Хәзерге заман хикәя фигыленең күплек санда юклык формасында зат-сан белән төрләнеше | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыленең күплек санда юклык формасында зат-сан белән төрләндерә белү | Китапханәчедән китап сорый, китапның нәрсә турында икәнен әйтү. Ничә китап укыганыңны әйтү, иптәшеңнән сорау | Ничә китап укыганыңны әйтү, әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү |
| | **Тема “Көндәлек режим” (2 сәгать)** | | | | | | |
| 17 | Сәгать ничә? конструк циясе | 1 | | | Сәгать ничә икәнен әйтә белү | Вакытны сорау, әйтү | Сәгатьне белү күнекмәләре формалаштыру |
| 18 | Вакыт рәвешләрен җөмләдә куллану | 1 | | | Үткән заман хикәя фигыль формасы, зат-санда төрләндерә белү | Үзеңнең көндәлек режимың турында сөйләү | Уку эшчәнлеген оештыру, аралашу күнекмәләрен камилләштерү |
| | **Тема “Ашханәдә”(8 сәгать)** | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 19 | Күләм һәм тәртип саннары. (20-100) | 1 | | | Күләм һәм тәртип саннарын (20-100) өйрәнү | Ашханәдә ашаганыңны, нәрсә ашаганыңны әйтү | Сөйләм берәмлекләрен логик эзлеклелеккә салу |
| 20 | Җыю саннары | 1 | | | Җыю саннарын сөйләмдә куллана белү | Дустыңның нинди ризыклар ятрканын сорау | Җөмләләр төзү, фикереңне төгәл итеп җиткерү |
| 21 | Боерык фигыль формасы | 1 | | | Боерык фигыль формасын белү | Савыт-сабаларны сөртергә кушу | Боерык фигыль формасын истә калдыру |
| 22 | Исемнең төшем килеше | 1 | | | Исемнең төшем килешен белү | Табын әзерләү тәртибен әйтү, сорый белү | Төшем килешенә беткән исемнәр язу |
| 23 | Янында бәйлек сүзе | 1 | | | Янында бәйлек сүзен сөйләмдә куллана белү. | Нәрсә янына килгәнеңне, нәрсә янында уйнаганыңны, нәрсә яныннан киткәнеңне әйтү | Янында бәйлек сүзе белән җөмләләр төзү |
| 24 | Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә төрләнүе | 1 | | | Исемнәрнең юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешендә төрләнүен белү | Предметларның урынын әйтү | Җөмләләр төзү, сорау-җавап, диалоглар төзеп сөйләшү |
| 25 | Уйный башладым төзелмәсе | 1 | | | Уйный башладым төзелмәсен белү | Нәрсә эшли башлаганыңны әйтү. | Уйный башладым төзелмәсенең кулланылышы, әңгәмәдәшең белән аралашу |
| 26 | Исемнең иялек килеше | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыльнең II, III зат күплек сан формаларын белү | Нәрсә ашаганыңны, нәрсә эчкәнеңне әйтү. | Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү |
| **Тема "Без әти-әниләргә булышабыз" (7 сәгать)** | | | | | | | |
| 27 | Аның китабы, аның әнисе төзелмәләре | 1 | | | Аның китабы, аның әнисе төзелмәләре, шагыйрь, бөек сүзләрен өйрәнү | Бөек татар, рус шагыйрләре турында сөйләү | Аның китабы, аның әнисе төзелмәләрен кулланышка кертү |
| 28 | -чы/-че сүз ясагыч кушымчасы | 1 | | | Яшелчә, үстерә, йорт төзи, төзүче, тегүче, сатучы, табиб сүзләрен өйрәнү | Тәртип саны, -чы/-че сүз ясагыч кушым-чаларын куллану | Сүзлек өстендә эшләү, -чы/-че сүз ясагыч кушымчасына сүзләр язу, истә калдыру |
| 29 | Минем әти-әнием кем булып кайда эшли | 1 | | | Һөнәр исемнәрен ясый белү | Үти-әниеңнең кем булып кайда эшләгәнен әйтү | Диалогка калган репликаларны өстәп уку |
| 30 | Күчереп язу "Безнең гаилә" | 1 | | | Күчереп яза белү | Грамоталы итеп язу күнекмәләренә ия булу | Дөрес, аңлаешлы итеп язу Күчереп язу |
| 31 | Хаталар өстендә эш. | 1 | | | Үзең эшләгән эшләрне сәйли белү | Син иртән нишлисең? | Хаталар өстендә эшләү. |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Без өйдә булышабыз | | | | | соравын куя һәм аңа җавап бирү | Җөмләләрне тәрҗемә итү |
| 32 | Үз алмашлыгының тартым белән төрләнеше | 1 | | | Өйдә үзең эшләгән эшләрне сөйли белү | Иптәшеңә сорау бирү, үрнәк буенча җөмлә төзү | Алмашлыкларның тартым белән төрләндерү |
| 33 | Ни өчен? соравы, чөнки, шуңа күрә теркәгечләре | 1 | | | Эшчән, тырыш, ялкау, эш яратмый, әдәпле, игътибарлы сүзләрен өйрәнү | Ни өчен соравы, чөнки, шуңа күрә теркәгечләрен сөйләмдә куллану | Ишетеп аңлау күнегүләре, җөмләләр төзү, диалог төзү, язу күнегүләре |
| **Тема “Туган якка кыш килде” (9 сәгать)** | | | | | | | |
| 34 | Сыйфат. | 1 | | | Кар бабай, Кар кызы, ясады, бии, җырлый, бизи, уенчыклар сүзләрен лексикага кертү. | Яңа ел бәйрәме белән котлау. | “Яшел чыршы” шигырен сәнгатьле уку күнекмәләре |
| 35 | Сүзлек диктанты<br>“Спорт уеннары”<br>Синоним сыйфатлар | 1 | | | Чаңгы, тимераяк, кәшәкә, чана, шуабыз, Кар бабай, ясыйбыз, Кар кызы сүзләрен өйрәнү | Сүзләрне грамоталы итеп яза белү | Сүзләрне язу, бәйрәм турында сөйләү<br>Сүзлек диктанты |
| 36 | Антоним сыйфатлар | 1 | | | Кыш, салкын, кар ява, җил, буран була, тау сүзләрен өйрәнү | Кыш айларын атау, кыш турында сөйләү | “Салкын саф һава” шигыре өстендә эш |
| 37 | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе | 1 | | | Сыйфатларны кулланып җөмләләр төзи белү | Антоним сыйфатларны кулланып сөйләү | Исемнәргә туры килгән сыйфатларны табу |
| 38 | Сыйфатның кимлек дәрәҗәсе | 1 | | | Исемнәрнең I, II зат берлек сан тартым белән төрләнүен белү | Һава торышын сорау, әйтү | Термометрга карап һава торышы турында сөйләү |
| 39 | Синоним, антоним сыйфатларны кабатлау | 1 | | | Синоним, антоним сыйфатларна сөйләмдә куллана, бара, уйный, шуа, кайта, китә фигыльләрен куллана белү | Кышкы уен төрләрен әйтү, уенга чакыру, тауга баруыңны әйтү | Хәзерге заман, үткән заман хикәя фигылен кулланып сөйләү |
| 40 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | 1 | | | Исемнәрнең зат-санда төрләнешен белү | Фигыльләрне үрнәк буенча үзгәртү | Хикәя уку, сорауларга җавап бирү |
| 41 | Һәрвакыт рәвеше | 1 | | | Чаңгы ярышы, сынды, һәрвакыт, бервакыт, егылды, якын сүзләрен өйрәнү | Чаңгы ярышы турында сөйләү | Исемнәрнең затын үзгәртеп сөйләү |
| 42 | Үткән заман хикәя фигыльнең юклык формасы | 1 | | | Көтте, авыл, бүләк итте, әбәкле, шаярды сүзләрен өйрәнү | Әби-бабайларның кайда яшәгәнен сорау, әйтү | Боерык фигыльнең 2 зат күплек сан формасын куллану |
| **Тема “Шәһәрдә һәм авылда” (5 сәгать)** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 43 | Хәзерге заман хикәя фигыль | 1 | | | Хәзерге заман хикәя фигыльләрен сөйләмдә кулланырга өйрәнү | Татарстан шәһәрләре-нең, елгаларының атамаларын әйтү | Ишетеп аңлау күнегүләре, җөмләләр төзү, диалог төзү |
| 44 | Хәзерге заман хикәя фигыльнең юклыкта зат-сан белән төрләнеше | 1 | | | Мин Казанга автобуста баруыңны, бармавыңны әйтә белү | Мәктәпкә нинди транспортта барганыңны сөйләү | Сүзлек өстендә эш. Җөмләләр төзү, сорау-җавап күнегүләре |
| 45 | Һәр, һәркем билгеләү алмашлыклары | 1 | | | Балык тотабыз, су коенабыз;<br>Һәр, һәркем алмашлыклары белән җөмләләр төзи белү | Кайсы урамда яшәгәнеңне сөйләү | Казан шәһәре, Бауман урамында төзелмәсе: кайсы? соравына җавап |
| 46 | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе | 1 | | | Зур – зуррак, матур – матуррак, кечкенә – кечкенәрәк төшенчәсе | Сыйфат дәрәҗәләрен кулланып сөйләү | Ишетеп аңлау күнегүләре, сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсен кулланып җөмләләр төзү |
| 47 | Һәр, барлык – билгеләү алмашлыклары | 1 | | | Янында, алдында, артында, эчендә бәйлек сүзләре, һәр, барлык сүзләрен өйрәнү | Авыл табигате турында сөйләү. | Җәйге һәм кышкы уен төрләре турында сөйләшү |
| **Тема “Әдәпле булыйк” (5 сәгать)** | | | | | | | |
| 48 | Билгеле үткән заман хикәя фигыльнең юклыкта зат-сан белән төрләнеше | 1 | | | Хәзерге заман, үткән заман хикәя фигыльнең зат-санда төрләнешен белү | Килгән кунакларны каршылау, әдәпле сүзләр куллану | Туган көн уеннарын белү, әңгәмәдәшең белән фикерләшү |
| 49 | Сүзлек диктант.<br>Билгеле үткән заман хикәя фигыль. Кабатлау | 1 | | | Сүзләрне яза белү. | Сүзләрне ишетеп грамоталы итеп язу. | Сүзлек диктанты язу<br>Сүзлек диктанты |
| 50 | Инфинитив | 1 | | | Өйрәнгән сүзләрне ныгыту | Кемне? Нәрсәне? сорауларына җавап | “Трамвайда” хикәя язу, матур язу күнекмәләре бирү |
| 51 | Исемнәрнең төшем килеше формасы | 1 | | | Алма, татлы, сәгать, орлыклар, бакчага, ярты сүзләрен өйрәнү | Дустыңның авыруы, аңа ярдәм итү турында әйтү | Хикәяне сәнгатьле уку, эчтәлеген сөйләү, уку эшчәнлеген оештыру |
| 52 | Үзенең сумкасы төзелмәсе | 1 | | | Үзенең сумкасы төзелмәсен өйрәнү | Дустыңны кунакка чакыру, телефоннан сөйләшү күнегүләре | Үзенең сумкасы төзелмәсен истә калдыру, диалог төзү |
| **Тема “Кечкенә дусларыбыз” (6 сәгать)** | | | | | | | |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 53 | Ул алмашлыгының юнәлеш, төшем килеше | 1 | | | Кем? Кемне? Кемгә? сораулары; көн саен төзелмәсе | Кемгә дә булса (Кәримгә, аңа) әйбер биргәнне әйтү | Ул алмашлыгының юнәлеш, төшем килешендә килүе |
| 54 | Көн саен төзелмәсе | 1 | | | Көн, атна, ел саен, һәр сүзләрен өйрәнү | Кемне (Кәримне, аны) дә булса яратканыңны әйтү | Көн саен төзелмәсен кертеп диалоглар төзү |
| 55 | Ул алмашлыгының килешләр белән төрләнеше | 1 | | | Терелде, тәпи, өрә, саклый, хуҗа, авырта сүзләрен өйрәнү | Чөнки, шуңа күрә сүзләрен кулланып сөйләү | Хикәяне дөрес уку күнекмәләре формалаштыру |
| 56 | Кебек (шикелле) бәйлеге | 1 | | | Кебек, шикелле бәйлек сүзләрен өйрәнү | Җөмләләргә сорау кую | Песиләрнең тышкы кыяфәтләрен сурәтләп сөйләү |
| 57 | Сыйфатның артыклык һәм чагыштыру дәрәҗәләре | 1 | | | Йорт, песи, эт, әтәч, кәҗә, кич, гел, бергә, бәхәслә-шәләр сүзләрен белүне ныгыту | Кемнең нәрсә яратканын әйтә белү. | Сыйфатның артыклык һәм чагыштыру дәрәҗәләрен кулланып сүзләр, җөмләләр төзү |
| 58 | “Кечкенә дусларыбыз” темасын кабатлау. | 1 | | | Сүзләрне дөрес яза белүне ныгыту. Сыйфат дәрәҗәләрен куллана белү | Матур язу күнекмәләре | Сыйфатның төрле дәрәҗәләрен кулланып сүзләр, җөмләләр төзү |
| **Тема “Күңелле җәй” (10 сәгать)** | | | | | | | |
| 59 | “Чөнки, шуңа күрә” теркәгечле кушма җөмлә. | 1 | | | Ямьле,күбәләк, эссе,җәйге, уку, тәмамланды, озын, кыска сүзләрен сөйләмдә куллана белү | Ел фасылларының исемнәрен белү, әйтү | Җәй көне укулар тәмамланганын әйтү. Җәй турында сөйләү |
| 60 | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе | 1 | | | Иң, дус, тату, гел, бергә, канат сүзләрен белүне ныгыту | Предметларның билгеләрен чагыштырып әйтү | Сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсен кабатлауга җөмләләр төзү |
| 61 | Кая? Кайда? Кайдан? сораулары | 1 | | | Җиләк, җыям, алан, чиләк, дәү әни, тотам сүзләрен сөйләмдә куллана белү | Урманга барганыңны, урманда җиләк җыйганыңны әйтү | Кая? Кайда? Кайдан? сорауларына җавап бирү, сөйләү |
| 62 | Әле, инде кисәкчәләре | 1 | | | Әле, инде кисәкчәләрен өйрәнү | Сүзләрне ишетеп грамоталы итеп дөрес язу | Сүзләрне язу. “Җиләк җыям, как коям” уенынсәхнәләштерү |
| 63 | Капма-каршы мәгънәле сүзтезмәләр | 1 | | | Каян? соравы. Тагын, пешер, яме, даруханә, каймак | Бер-береңне табынга чакыра, ашаганнан соң | Предметны каян алганыңны сорау, җавап бирү |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | сүзләрен сөйләмдә куллана белү | рәхмәт әйтү | күнекмәләрен формалаштыру |
| 64 | Аергыч | 1 | | | Җөмләдә аергычны табарга өйрәнү | Сүзләрне грамоталы итеп дөрес язу | Мөстәкыйль эшли белү |
| 65 | -мы,-ме кушымчалы сорау җөмләләр | 1 | | | Су коена, йөзә, суга сикерә, кәймәдә йөзә, чума, кызына сүзләрен сөйләмдә куллана белү | Су керергә чакыру | Җәйге ял турында сөйләү |
| 66 | Җөмләнең баш кисәкләре | 1 | | | Су коена, йөзә, суга сикерә, кәймәдә йөзә, чума, кызына сүзләрен белүне ныгыту | Су коену турында җөмләләр төзү | Рәсемнәр буенча хикәя төзү, коммуникатив мәсьәләгә таянып, фикерне төгәл итеп җиткерү |
| 67 | Җөмләнең иярчен кисәкләре | 1 | | | Сабантуй, баганага менә, уен, чүлмәк, көрәшә сүзләрен өйрәнү | Сабантуйда катнашу турында сөйләү | Сабантуй турында хикәя язу, фикер алышу |
| 68 | Кабатлау дәресе | 1 | | | Өйрәнгән сүзләрне белүне ныгыту | Сорау - җавап күнегүләре | Җәйгә биремнәр бирү |

**Язу һәм язма сөйләм күнекмәләрен тикшерү өчен биремнәр:**

- аерым сүзләрне, җөмләләрне, бәйләнешле текстны үзгәрешсез күчереп язу;
- нокталар урынына кирәкле хәрефләрне, сүзләрне куеп , җөмләләрне күчереп язу;
- диктант язу һ.б.;
- изложение, сочинение өйрәтү рәвешендәге язма эшләр буларак кына кулланыла;

Агымдагы, тематик тикшерүләрне оештыру өчен тестлар куллану уңайлы. Алар тикшерү эшен тиз һәм төгәл оештыруны тәэмин итә.

**Язу:** Орфографик (хәреф төшерү, өстәү, алыштыру, сүзләрне юлдан юлга дөрес күчермәү) хаталарга гына игътибар ителә; Әгәр дә сүз берничә урында дөрес,

ә аерым бер урында хаталы язылган икән, бу ялгыш дип саналмый. Бер үк хата берничә сүздә кабатланса, бу бер ялгыш дип исәпләнә.

**Күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә итеп язылган, орфографик хаталары булмаган, ләкин 1-2 җирдә хәрефләрнең урыны алышынган булса, **"5"ле** куела. Эш бик ук чиста итеп башкарылмаса; 1-2 хата җибәрелсә; хәрефләрнең урыны алышынса, 1-3 төзәтүе булса, **"4"ле** куела. Язуда 3-5 хата җибәрелсә яки хәрефләрнең урыны алышынса; 4-5 төзәтүе булса, текст пөхтә итеп язылмаса; төзәтүләр булса, **"3"ле** куела. Хаталар саны 6 дан артса; төзәтүләр күп булса**, "2"**ле куела.

**Сүзлек диктанты һәм аны бәяләү**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә **"5"ле** куела. Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1-3 төзәтүе яки 1-2 орфографик хатасы булган эшкә "**4"ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4-5 төзәтүе яки 3-5 орфографик хатасы булган эшкә **"3"**ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә **"2"ле** куела.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик, 1 пунктуацион хатасы булган диктантка **"5"ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2-3 орфографик, 2-3 пунктуацион хатасы булган диктантка **"4"ле** куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4-6 орфографик, 6 пунктуацион хатасы булган диктантка **"3"ле** куела.

Пөхтә язылмаган, 7 дән артык орфографик, 7 дән артык пунктуацион хатасы булган диктантка **"2"ле** куела.

**МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЧЫГАНАКЛАРЫ**

| | УМК | Укытучы өчен методик әдәбият | Укучылар өчен әдәбият |
|---|---|---|---|
| 3. | 1. Р.З.Хәйдәрова, Г.М.Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина “Күңелле татар теле”. Дүртьеллык башлангыч мәктәпнең 3 нче сыйныф рус балалары өчен татар теле һәм уку дәреслеге. Ике кисәктә. Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 нче ел.<br><br>2. Кассеталар, таблицалар, татар язучыларының портретлары, аудио-аппаратура һ. б.<br><br>3. Рус телендә баларга татар теле һәм әдәбиятын коммуникатив технология нигезендә укыту программасы, 1 – 11 нче сыйныфлар, Казан: Татар китап нәшрияты, 2011. Төзүчеләр: Р.З. Хәйдәрова, Р.Л.Малафеева (программа федераль дәүләт белем стандартларына (ФГОС) нигезләнеп төзелгән) | 1. Р.З.Хәйдарова, Л.Ә. Гыйниятуллина, Г.И. Газизуллина “Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укыту”, 3 сыйныф, Казан, “Татармультфильм” нәшрияты, 2013 нче ел. | 1. Ф.С.Сафиуллина “ Базовый татарско-русский и русско-татарский словарь для школьников”Казань,ТАРИХ, 2012<br><br>2. Программа буенча каралган язучыларның әсәрләре<br><br>3. Р.З.Хайдарова, Р.Л.Малафеева “Татар теле таблицаларда”(рус телле укучылар өчен), Яр Чаллы, 2005 ел<br>Электрон ресурслар:<br>http://edu.tatar.ru/<br>http://www.suzltk.ru/<br>http://www.mtss.ru/corse/<br>http://Kitap.net.ru/<br>http://tatar.com.ru/<br>http://mon.tatar.ru/<br>сайт МО и НРТ |